Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

№1 (19)

Октябрь-ноябрь, 2016 нчы ел

**Бу санда:**

*Гимназия сулышы* 1-3

*Сиңа әйтер сүзем бар, әнием* 4-5

*Иң популяр 10 һөнәр* 6-7

*Укучы мөнбәре* 8

**Аналар турында татар халык мәкальләре**

*Ана – шәфкать диңгезе.*

*Ана яхшылыгын авырсаң белерсен.*

*Анаңдай ана булмас.*

*Анасыз корт бал җыймас,*
*бал җыйса да мул җыймас.*

*Тән бирган дә - ана,*
*сөт бирганда - ана,*
*тел бирган дә - ана,*
*көй бирган дә - ана.*

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Ләйсән Фагимовна Бариева - Россия Федерациясенең “Иң яхшы укытучы” Гранты иясе



2016 елның 6 октябрендә Казан Ратушасында “Мәгариф” өстенлекле проекты кысаларында Россия Федерациясенең “Иң яхшы укытучы” Гранты ияләрен тәбрикләү тантанасы узды. Гимназиянең биология укытучысы **Ләйсән Фагимовна Бариева** бәйрәмдә конкурста җиңүче буларак катнашты. Тирән белемле, киң эрудицияле, компетентлы белгеч Ләйсән Фагимовна – укучыларның иң яраткан укытучысы. Зур уңышлар юлдаш булсын сезгә, хөрмәтле укытучыбыз!

### Мөслимдә “Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре”



“Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре” кысаларында Мөслим гимназиясендә язучылар белән очрашу кичәсе узды. Очрашуда якташларыбыз филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, баш фәнни сәркәтибе, Мөслимнең Әмәкәй авылы кызы Заһидуллина Дания Фатих кызы, тарих фәннәре докторы, Татарстан фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗәни исемендәге тарих институтының бүлек мөдире Заһидуллин Илдус Котдус улы катнашты. Прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, “Мәдәни җомга” газетасы баш редакторы Вахит Шәех улы Имамов белән очрашу укучыларда тирән эз калдырды. Балалар шагыйре, Татарстанның атказанган укытучысы, Мөслим муниципаль районының Мактаулы гражданины Әхмәтҗанов Мөҗәһит Заһит улы очрашуда балаларга үз шигырьләрен укыды, курай моңнарын бүләк итте. Барыбыз өчен дә дулкынландыргыч мизгелләр бүләк итүче иң кадерле кунак – шагыйрә, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Клара Гариф кызы Булатова булгандыр. Зал аның чыгышын тын да алмыйча тыңлады, алкышларга күмде. Мондый эчтәлектәге очрашулар күңелне баета, рухыбызны тәрбияли, иманыбызны ныгыта.

### Укытучылар спартакиадасы уңыш китерде

Гимназиябездә район мәктәпләре укытучылары арасында чираттагы спартакиада ярышлары узды. Укытучылар бергәлешеп иң җитез, иң көчле, иң ныклы спортсмен исемнәре өчен ярыштылар. Шәхси зачетта гер күтәрү буенча беренче урынны гимназиябез директоры А.Ф.Мирзаянов алды, шулай ук йөзү буенча беренче урынга физкультура укытучыбыз Д.Г.Шәйхетдинов лаек булды. Мәктәпара зачетта гимназиябез 4 нче урын яулады. Афәрин!

### Көзге баллар гөрләде

Гимназиябездә “Сөмбелә” бәйрәмен зур масштабта уздыру традициягә әверелде. Эстафетаны башлангыч сыйныф укучылары башлап җибәрде. Эчтәлекле шоу-программа тәкъдим ителде. “Алтын көз” күргәзмәсендә укучыларның кәгазьдән, агачтан, табигый материаллардан ясалган картиналарын, яшелчәләр, чәчәкләрдән тудырган искиткеч зәвык белән эшләнгән композицияләрен күрергә мөмкин иде. Урта һәм югары сыйныф укучылары “Көзге бал” бәйрәмнәре оештырды. Бәйрәмнәрдә бер генә укучы да читтә калмаган: кемдер костюмнар, биюләр, җыр, юмор әзерләгән, кайберәүләр көзге байлыктан композиция, икебана ясаган иде. Бәйрәмдә иң актив катнашкан сыйныфлар гимназия дирекциясенең Грамоталарына лаек булдылар.

# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

## Олыласак олыны, олыларлар үзеңне





Агымдагы елның 1-10 октябрендә Татарстанда Өлкәннәр декадасы узды. Бу декада кысаларында гимназиябездә зур бәйрәм - Өлкәннәр көне оештырылды. Һәр сыйныф класс сәгатенә кунак чакырды. Алар арасында гимназиядә күп еллар хезмәт куйган ветеран укытучылар Л.Ә.Талипова, Н.М.Насыйрова, Р.М.Мәрданшина, шулай ук укучыларның әби-бабалары бар иде. Балалар һәм укытучылар зур кунакларыбыз өчен концерт программасы, мул табын әзерләделәр. Өлкәннәр, үз чиратында, тормыш тәҗрибәләре белән уртаклаштырлар, укучыларга яхшы теләкләрен теләделәр.

4 нче а сыйныф укучылары М.А.Идиатуллина җитәкчелегендә “Буыннар очрашу”ы уздырды.

## Халкыбыз традицияләре сагында







Минзәлә шәһәре “Муса Җәлил исемендәге педагогия колледжы” базасында республика гимназияләре укучылары командалары арасында “Сөмбелә” бәйгесе уздырылды. 9 нчы а, б сыйныфы укучыларыннан торган Мөслим гимназиясе командасы, бәйгедә беренче урын яулады. Бәйге берничә этаптан оештырылган, квест-уен формасында барды. Командалар алдан әзерләнгән чыгышларын якладылар, аннары егетләр һәм кызлар аерым биремнәр үтәделәр. Компьютер тесты үтеп, татар халкының йола-бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, татар халкы тарихы, мәдәнияте, әдәбияты буенча белемнәрен сынадылар. Иң соңгы бәйге – иҗади осталык бәйгесе. Монда команданың бердәмлеге, капитанның оештыру сәләте, осталыгы сынала. Барлык бурычларны уңышлы үтәп, безнекеләр лаеклы рәвештә җиңүче булып кайттылар.

Команданың уңышы һәрбер катнашучының үз-үзенә җаваплылыгыннан тора. Ямалов Илнар белән Мәгъданова Ләйсән нәфис сүз осталары, Булат Әхмәтҗанов татар халык көйләрен курайда оста башкаручы булуы белән шаккаттырса, Айдар Шәйхетдинов белән Айгөл Сабитова табан астыннан ут чыгарып биюләре белән тамашачы симпатиясен яуладылар. Зиязова Миләүшә интеллектуаль бәйгедә иң күп балл җыючы зыялы кыз буларак, Фәхертдинова Айгөл осталык конкурсында иң фантазияле, зәвыклы кыз булуы белән башкалардан аерылып торды. Команда капитаны Нурлан Шәехов конкурсантлар арасында үзенең эчтәлекле чыгышы, сәхнәдә үзен тотышы, сәнгатьле сөйләме белән тамашачыны әсир итте. Жюри гимназия укучылары чыгышын режиссура ягыннан көчле куелуын аерым билгеләп үтте. Афәрин! Команданың идея җитәкчесе Э.В.Тимергалиева, музыка җитәкчесе – Г.Ә.Фәхретдинова.

## Республикакүләм информацион-филологик марафон җиңүчеләрен котлыйбыз



Минзәлә шәһәре “Муса Җәлил исемендәге педагогия колледжы” базасында 7-8-9 нчы сыйныф укучылары арасында республикакүләм информацион-филологик марафон узды. Бәйгедә укучылар 3 этапта көч сынаштылар: грамоталылык, теоретик белем, иҗади сәләтне ачыклау буенча ярышлар булды. Республиканың 13 шәһәре һәм 9 районыннан 248 катнашучы арасында “Мөслим гимназиясе” командасы 1 урынны яулады. 9 нчы а сыйныфы укучысы Миләүшә Зиязова татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләр арасында 1 урын, Эльвина Шамукаева татар телен чит тел буларак өйрәнүчеләр арасында 1 урын, 9 нчы б сыйныфы укучысы Айрат Латипов информатика буенча 2 урын, 8 нче а сыйныфы укучысы Регина Вәлиева рус теленнән 3 урын яулады. Укучыларны бәйгегә әзерләгән фәнни җитәкчеләр: татар теле укытучысы Э.В.Тимергалиева, информатика укытучысы – А.Р.Кадирова, рус теле укытучысы И.Т.Галиева. Гимназия коллективы данын яклап зур нәтиҗәләргә ирешкән егет-кызлар – безнең горурлыгыбыз. Уңышларыгыз дәвамлы булсын!

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ









### Гимназия хезмәткәрләренең “Туган якның милли моңнары” концертыннан фоторепортаж








### Театр яктылыкка, нурга илтә...



Гимназиябездә икенче ел инде “Балкыш” театр түгәрәге эшләп килә. Без әлеге түгәрәктә бик теләп шөгыльләнәбез. Җитәкчебез Ямалова Г. Ф. безне сәхнә нечкәлекләренә өйрәтә. Шулай ук мәктәп, район чараларында алып баручылар – конферанслар булырга әзерләнәбез. Сәнәдә чыгыш ясау, төрле рольләрдә уйнау безгә бик ошый, түгәрәктә шөгыльләнү укуда да ярдәм итә: үз-үзебезгә ышанычыбыз арта, теләсә кайсы аудитория каршында югалып калмаска өйрәнәбез.





Инде уңышларыбыз да байтак. Узган уку елында “Театр как театр” II Республика конкурсында катнашып, “Драматик театр” номинациясендә җиңүче булдык. Быел исә “Сәйяр” Республика театр фестиваль – бәйгенең район этабында 1 нче урын яулап, зона этабында чыгыш ясау хокукына ия булдык. Һәм менә, 18 нче ноябрь көнне Яр Чаллы шәһәрендә үткәрелгән зона турында уңышлы чыгыш ясап, “Татмедиа” җәмгыяте, “Сәхнә”, “Салават күпере” журналларының Мактау грамотасына лаек булдык.

Без – түгәрәктә шөгыльләнүче укучылар, иҗат дәрте белән илһамланып яшибез. Алдагы көннәрдә Г.Камалнын “Беренче театр” пьесасын сәхнәләштерергә әзерләнәбез, “Йолдызлык” фестивалендә уңышлы чыгыш ясарбыз дип өметләнәбез.

*Акмалова Лиана,*
*7 нче а сыйныфы укучысы*

# СИҢА ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР, ӘНИЕМ



## Ана дигән хәзинә

Әнкәй йорты – алтын бишек. Өйнең яме ана белән. Мәктәптән йөгерә-йөгерә өйгә кайтабыз, чөнки өйдә әни көтә. Эштән арып кайтса да, ул кояш кебек балкып тора. Бөтен серләребезне, кайгы-шатлыкларыбызны, әлбәттә, иң беренче чиратта, әниләребезгә сөйлибез.

Минем әнием – Ильмира, химия, биология фәннәрен укыта. Куллары алтын аның. Пешергән ризыклары – телеңне йотарлык. Әтиебез Радик белән безгә, абыем белән икебезгә, матур тәрбия бирергә тырышалар.

Тән биргән дә - ана, сөт биргән дә - ана, тел биргән дә - ана, көй биргән дә - ана. Әниләр алдында бурычыбызны беркайчан да түләп бетерә алмабыз. “Бер әнкәне мең нәнкә дә алыштыра алмас” дигән халык әйтеме минем йөрәгемә кереп калды. Аналарны кадерләп, яратып, йөзләренә кызыллык китермичә яшәргә тырышырга кирәк. Ана ул – хәзинә. Хәзинәне кадерләп сакларга кирәк.

***Инзилә Сәфәргалина,***
***10 нчы б сыйныфы укучысы***

## Әни йөрәге – иң сизгер йөрәк

Әни күзләре мәңге сүнмәс бәхет, шатлык уты белән яна. Әни йөрәге сизгер йөрәк булып кала. Әнинең мәрхәмәтле елмаюы гына ни тора!

Һәр кеше әнисен бик ярата. Ә минем өчен ул җир йөзендә иң якын, иң кадерле кеше. Ул безгә тормыш биргән, кадерләп, тәрбияләп үстергән.

Минем әнием вакытында назлый да, кирәгендә ачулана да белә. Аның биргән киңәшләрен мин һәрвакыт файдаланам. Әниемне мин бик яратам.

Әниләргә карата безнең мәхәббәтебез никадәр зур булса, тормышыбыз шулкадәр шатлыклы һәм якты булачак.

***Ринат Искәндәров,***
***10 нчы а сыйныфы укучысы***

## Әнием – ышанычлы терәгем

Миңа бу дөньяда иң кадерле кеше ул - әни. Әниемнең канаты астында үземне бәләкәй сары чебеш кенә итеп хис итәм. Миңа анда җылы, якты, йомшак, күңелемә тыныч, шуңа күрә үземдә ышаныч тоям.

Әнием минем ягымлы, сөйкемле, кешелекле, акыллы, эшчән. Ул - зур йөрәкле кеше. Аның күңел җылысы гаиләдәге өч балага да, әтиемә дә, әбиемә дә җитә.

Минем әнием фантазиягә бай. Ул үзе төрле рецептлар уйлап табарга, бөтенебезне шаккаттырырга ярата. Без беләбез: һәрвакыт безнең өстәлебез кайнар ризык, чәй тәмнәре белән тулы булачак. Мин әниемне бик тә нык яратам, һәм аңа озын гомер, сәламәтлек, хатын-кыз бәхете телим.

***Эльвина Солтанова,***
***10 нчы а сыйныфы укучысы***

## Балалык рәхмәтем

Әнием! Минем иң кадерле кешем! Мине яратучы да, мине аңлаучы да, кирәк чакларда ярдәм итүче дә син бит бу дөньяда! Синнән башка тормышымны мин күз алдыма да китерә алмыйм. Миңа, апаема, абыема син зур терәк, таяныч. Безгә тәмле ризыклар пешерүче дә, матур-матур киемнәр алучы да, изге теләкләр теләп мәктәпкә озатучы да, әни, әти, сез бит! Аллага шөкер, гаилә җылысын тоеп, үз өебездә, үз гаиләбез белән яшибез.

Саклап торсын, яклап торсын
Әнием, теләкләрең.
Гомерләреңә җитәрлек,
Балалык рәхмәтләрем.

***Язилә Исмәгыйлова,***
***10 нчы а сыйныфы укучысы***



## Котлау

Әни - ул дөньяда иң бөек кеше. Алар безне тугыз ай буе йөрәк түрләрендә йөртеп, безнең белән сөйләшеп, дөньяга китергәннәр, “бәбкәм” дип иркәләп кулларында назлаганнар, төн йокыларын йокламыйча, ару-талуларына карамыйча, безне бишектә тирбәтеп йоклатканнар, тәрбияләп үстергәннәр. Без аларга рәхмәтлебез, аларга беркайчан да кайгы, сагыш күрсәтергә тиеш түгел. Егерме жиденче ноябрь - әниләр көне. Без, унберенче сыйныф укучылары, чын күңелдән аларны бу шатлыклы бәйрәм белән котлыйбыз! Сезгә озын гомер, ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете, эшегездә зур уңышларга ирешүегезне телибез. Балаларыгызның куанычын күреп яшәгез! Тормышыгызда барлык теләкләрегез чынга ашсын! Үз чиратыбызда, без дә сезнең өметышанычларыгызны акларга тырышырбыз. Безнең өчен сезгә кызарырга туры килмәс. Без - сезнең горурлыгыгыз булырбыз!

***Иң изге теләкләре белән***
***11 нче сыйныф укучылары***

## О С Т А Х А Н Ә

***Хәзерге модада, шулай ук трендта үз кулың белән эшләнгән әйберләр югары бәяләнә. Яшь кызлар, модадан һәм заман тенденцияләреннән калышмас өчен, үзләренең эксклюзив булуларын исбат итү өчен, киемгә кулдан эшләнгән элементлар, детальләр өстиләр.***



Пэчворк – вак-төяк тукыма кисәкләреннән креатив тегү алымы. Моннан 300 еллар элек Англия, Америка мастерлары арасында популяр булган бу шөгыль “Текстильная мозаика” дип йөртелгән була. Пэчворк йорт җиһазларын (диван, кресло), йомшак эшләнмәләр (плед, коврик, покрывало), интерьер бизәү өчен кулланыла. Пэчворк белән эшләнгән жилет, кофта, юбка, сумкалар бик матур чыга. Эшне эскиз төзүдән, төсләрне туры китереп сайлаудан башларга кирәк. Әлбәттә, бик җентекләп, төгәл итеп эшләргә, тукымаларны пөхтә итеп ялгарга кирәк. Мастерлар бу өлкәдә чын шедеврлар тудыра.



Кинусайга – энә-җепсез генә эшләнә торган пэчворк. Аны пенопласт нигезгә ясыйлар. Рәсемне төшергәч, эз буенча тирән уемнар сызыла, тукыма кисәкләрен эзгә очлы предмет белән кертеп урнаштырып барырга гына кирәк. Кинусайга бүлмәләрне бизәү өчен кулланыла.

Әниләр өчен баласының үз куллары белән ясаган бүләгеннән дә кадерле бүләк була алмый. Башкалардан аерылып торган үзенчәлекле бүләк ясарга уйласагыз, безгә кушылыгыз. Креатив кул эшләре белән танышырга телисезме? Әйдәгез, бергәләп өйрәник. Квилинг, оригами, кусудама – кәгазьдән эшләргә яратучылар өчен бик таныш. Технология дәресләрендә без матур паннолар, кабарынкы уенчыклар, купшы аккошлар, төрле чәчәкләр ясарга өйрәндек. Әлбәттә, әниләребезгә андый эшләребезне бүләк итеп тә сөендерә алабыз. Тагын башка төрле нинди кул эшләнмәләре бар микән? Истәлекле дә, файдалы да бүләк ясарга иде. Бар андый нәрсәләр.



Скрапбукинг турында ишеткәнегез бармы? Скрапбукинг – кулдан эшләнгән фотоальбом. Онытылып беткән фотоларны яңа альбомга урнаштырып, матур бизәкләргә төреп бирсәң, әниләр бик шат булыр. Бизәү өчен тукыма, открытка, төрле алымнар белән ясалган чәчәкләр, орнаментлар кулланырга була. Кайчы, клей, төсле кәгазь, тукыма алыйк та эшкә тотыныйк.

Кардмейкинг – үз кулларың белән ясаган открытка. Аңа әниләрнең йөрәгенә үтеп керерлек җылы, назлы сүзләрне язарга була.

Болардан тыш гильошинирование алымы белән салфетка, яка, бант, киемгә брошка урынына куярлык күбәләк ясарга мөмкин. Тукыманы яндырып эшләү өчен махсус прибор кирәк булачак.

Ә малайлар әниләргә нәрсә бүләк итә ала? Әлбәттә, станокта кырып ясаган кухня кирәк-яракларын һәр укучы да инде бүләк итте, чөнки боларны технология дәресендә эшләргә өйрәнделәр. Тәҗрибә ясап карарга яратучылар пыяладан төрле төстәге төймәләр ясый ала. Бу алым лэмпворк дип атала.



Пирография – агачны яндырып картина ясау (выжигание по дереву). Рәсемне фанерага төшерергә, аннары махсус прибор белән агачны яндырырга кирәк.




Твистингны кызлар да, малайлар да ясый ала. Шарлар ярдәмендә модельләштерү твистинг дип атала. Фантазиягезне эшкә җигегез дә эшкә тотыныгыз, дуслар! Әниләрегезне үз кулларыгыз белән ясаган шедеврлар белән сөендерергә ашыгыгыз! Уңышлар телим!

***Эльвина Солтанова,***
***10а сыйныфы укучысы***

## ЧЫГАРЫЛЫШ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН МАХСУС КУШЫМТА

# ИҢ ПОПУЛЯР 10 ҺӨНӘР: НИ ЭШЛИСЕ, КАЙДА УКЫЙСЫ, ХЕЗМӘТ ХАКЫ



***Һөнәр сайлау – кеше тормышындагы иң авыр һәм җаваплы адым.*** *Дөрес сайланган һөнәр – тормышта үз урыныңны табу, дигән сүз. Күпләр, киңәш сорап, әти-әниләренә, дуслары, туганнарына мөрәҗәгать итә. Әмма башка кеше киңәшләре дөрес булмаска да мөмкин, чөнки һәркем дөньяга үз күзлегеннән карый. Нәтиҗәдә, теге яки бу һөнәрне сайлаганнан соң, кеше кайчак аның үзенә бөтенләй туры килмәвен аңлый.*


*Киләчәктә хезмәтеңне дөрес сайлар өчен төрле һөнәр ияләренең ничек һәм нәрсәләр эшләвен белергә кирәк. Һөнәрнең рухи һәм матди үсеш өчен нинди мөмкинлекләр бирүенә дә игътибар итми ярамый, бу бит синең алдагы тормышыңның нинди булачагын билгели. Абруй дигән төшенчә дә бик мөһим бүгенге көндә. Үз шәхси сыйфатларыңны, мөмкинлек-ләреңне (темперамент, харак-тер, сәламәтлек, гыйлем һ.б.) исәпкә алу да соңгы урында булмасын. Син сайлаган һөнәр бик кызыклы да, абруйлы да булырга мөмкин, әмма әле уку йортын сайлаганчы ук, бүгенге көндә син шул белгечлек буенча кайда эшли алачагыңны да күзалларга кирәк.*

Ел саен хезмәт базары белгечләре иң абруйлы һөнәрләр исемлеген игълан итә. Иң яхшы эш нинди соң ул? Россия базары тәкъдим иткән исемлек һәм саннарга күз салыйк.

**Адвокат.** Инде 15 ел дәвамында әлеге һөнәр ирләр



арасында да, хатын-кызлар арасында да популярлыгын югалтмый. Юридик факультетка укырга керү бик авыр, чөнки юрист булырга теләүчеләр саны вузлардагы урыннарга караганда күпкә зуррак. Аның караве, адвокат дипломына ия булучылар зур хезмәт хакы алып, абруйлы фирмада эшләячәгенә ышана ала. Хезмәт хакы – якынча 30 000-150 000 сум.



**IT-белгеч.** Информацион технологияләр белән эшләү абруйлы да, кирәкле дә, бүгенге көндә бик модадагы да хезмәт. 2015 елның «Иң күп хезмәт хакы алучы һөнәрләр» исемлегендә программистлар статусы буенча да, эш хакы буенча адвокатлар белән бер дәрәҗәдә йөри. Тагын бер ягы: әлеге өлкәдә хезмәт куючы осталар бер урында гына утырмыйча, берничә оешмада эшләргә дә өлгерә. Димәк, программист булсагыз, югалып калмыйсыз һәм ач утырмыйсыз дигән сүз. Хезмәт хакы – якынча 60 000-300 000 сум.

**Хисапчы.** Тәҗрибәле хисапчы беркайчан да эшсез утырмый. Әлеге һөнәр ияләренә шулай ук югары оклад гарантияләнә. Хезмәт хакы – якынча 40 000-200 000 сум.

**Психолог.** Әлеге һөнәр кызыклы кешеләр белән аралашырга, төрле семинарларда, күчмә утырышларда катнашырга мөмкинлек бирә. Югары хезмәт хакыннан тыш, психологлар кешеләр арасындагы мөнәсә-бәтләрне тирән аңлый, кешеләрнең характерын, табигатен, үз-үзен тотышын, кеше гамәлләренә нинди факторлар тәэсир итүен җентекләп өйрәнә. Хезмәт хакы – якынча 32 000-120 000 сум.




**Менеджер.** Әлеге сүзне бүген күптөрле мәгънәдә аңлап һәм аңлатып була. Менеджер вазыйфасы хәзер берничә хезмәткәрдән торган кечкенә генә компанияләрдә дә бар. Хәзер бу сүзне урынлы да, урынсыз да кулланалар.

Менеджерның беренчел мәгънәсе – башкаларның эшчәнлеге белән идарә итү. Клиентлар белән эшләү, хезмәт һәм товар тәкъдим итү, реклама үсеше белән шөгыльләнү – менеджерның төп вазыйфалары әнә шулар.

Менеджерлар арасында иерархия дә бар: түбән буын менеджерлары – болар, нигездә, кибет бүлекләренең җитәкчеләре, сату эше белән турыдан-туры идарә итүчеләр, кафедра җитәкчеләре. Урта буын менеджерлар – сату-алу, товар белән эш итүче түбән буын менеджерлары белән идарә итүчеләр, ягъни цех, филиал җитәкчеләре, уку йортларында деканнар һ.б. Югары буын менеджерларына генераль директорлар, сәүдә үзәге җитәкчеләре һәм башкалар. Шундый төр зур коллектив һәм тармаклы эшчәнлек белән җитәкчелек итүчеләр кирә.

Хезмәт хакы – якынча 25000-250 000 сум.

## ЧЫГАРЫЛЫШ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН МАХСУС КУШЫМТА



**Модельер.** Әлеге һөнәргә вакансияләр күп түгел. Бәлки бу Россиягә миллионлаган мода белгече кирәкмәвенә бәйледер. Шулай да бу һөнәр – иң абруйлылардан санала, чөнки иҗади эшләргә һәм мода яңалыкларыннан хәбәрдар булырга мөмкинлек бирә. Хезмәт хакы – якынча 20 000-65 000 сум.



**Банк хезмәткәре.** 2015 елның «Иң күп хезмәт хакы алучы һөнәрләре» исемлегендә бу белгечлек – 4 нче урында. Гадәттә тәҗрибәле банк хезмәткәрләренә ихтыяҗ зур. Менә диген эш шартлары, югары хезмәт хакы, карьера үсеше һәм һәрвакыт ихтыяҗ булу – әлеге һөнәрнең төп сыйфатлары. Хезмәт хакы – якынча 60 000 тирәсе.



**Маркетолог.** Товар, хезмәт тәкъдим итү, базар ихтыяҗларын өйрәнү белән шөгыльләнүче белгеч. Әлеге һөнәр дә абруйлылар рәтендә, чөнки маркетолог – җәмгыятьтәге бер генә күңелле кичәне дә калдырмый. Хезмәт хакы – якынча 20 000-120 000 сум.

**Табиб.** Бу һөнәргә ия булыр



өчен башкаларга караганда күбрәк вакыт сарыф итәлә. Үзен медицина өлкәсе белән бәйләргә телүчеләргә 7 дән алып 10 елга кадәр югары уку йорты баскычларын таптарга туры киләчәк. Аның каравы, укып чыгып, гамәли күнекмә узган студент иң кирәкле һәм әһәмиятле һөнәр ияләренең берсенә әйләнә. Шәхси медицина учреждениеләренең күп булуын да исәптә тотсак, димәк бу еллар эчендә үзләштерелгән һөнәр яхшы хезмәт хакы белән дә тәэмин итә. Хезмәт хакы – якынча 50 000-200 000 сум.

**Реклама өлкәсендә белгеч.** Чит илләрдә һәм инде бүгенге Россиядә дә бу һөнәр үтә популяр һәм керемле санала. Әмма Татарстанда әле ул киң колач җәйде дип әйтеп булмый. Гадәттә, оешмалар реклама белгече буларак чакырылган белгечләр гадәти менеджерлык эше белән шөгыльләнергә, телефонда утырырга мәҗбүр булалар. Әмма бу һөнәр – киләчәк һөнәре, шуңа да аны сайларга теләүчеләр булса, тәвәккәлләргә кирәк, дип уйлыйм. Киләчәктә чын татар брендларын танытучыларга әверелергә мөмкиннәр бит алар. Хезмәт хакы – 100 000 сумга кадәр.

*Югарыда санап үтелгән һөнәрләрнең абруйлы булуларына карамастан, белгечләр бу исемлек якын киләчәктә үзгәрәчәк дип ышандыра. Бүген модада булган күпсанлы профессияләр киләчәктәге «абруйлы һөнәрләр» исемлегенә бөтенләй эләкмәскә мөмкин. Фаразларга караганда, берничә елдан техник белгечлекләрнең абруе күпкә зуррак булачак. Югары баскычларның берсендә инженер һөнәре торыр дип уйлыйлар.*

***P.S.*** *Интернет бер урында тик утыра белми торган кешеләр өчен дә аерым һөнәрләр исемлеге тәкъдим итә. Монысында беренче баскычта журналист эше тора. Исемлектә шулай ук бәйрәмнәр оештыручы, реклама белгече, копирайтер, экскурсияләр оештыручы, укытучы һөнәрләре дә кертелгән.*

## КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР



Борынгы Русьта иң мактаулы эшләрнең берсе булып **төкерүче**, икенче төрле әйткәндә, **шалкан утыртучы** һөнәре саналган. Шалканның орлыклары бик вак, бер килограммда миллионнан артык орлык була. Аны кул белән утырту мөмкин түгел. Шуңа орлыкларны яхшы итеп төкереп утыртучыларны бик бәялəгәннәр.

Бөекбританиядә хәзерге көндә бик тә популяр яңа һөнәрләрнең берсе – **чиратта торучы** һөнәре. Бу эшнең бер сәгате өчен сатып алучы 20 фунт (безнеңчә, 2 000 сум чамасы) акча түли.

Япониядә дә кызыклы һөнәр бар – **колак чистарту буенча белгеч**. Бу эшне матурлык салоннарында махсус укытылган кызлар башкара.

Беләсезме, юкмы икән, пингвиннар бер аркаларына ауса, үзләре генә аякка баса алмый. Шул сәбәпле, полюслардагы самолетлар еш оча торган станцияләрдә **пингвиннарга ярдәм итүче кешеләр** эшли. Астагы кошлар очкычның хәрәкәтен карыйм дип артык каерылып аркаларына аугач, «пингвин ярдәмчеләре» кошларны торгызып йөри.

***"Ялкын" журналы материаллары файдаланылды***

## У К У Ч Ы   М Ө Н Б Ә Р Е

### Гимназиядә барлык фәннәрне татар телендә укытуга карата фикерегез ничек?

***Шул сорау белән 11 нче сыйныф укучыларына мөрәҗәгать иттек.***

Татар телендә укуның да, рус телендә укуның да үз өстенлекләре һәм кимчелекләре бар. Минемчә, татар телендә уку татар балалары өчен яхшы, ләкин аларга мәктәпне бетергәннән соң авыр булачак. Татар һәм рус мәктәпләрен аерым итәргә кирәктер. Ата-аналар балаларын кайда тели, шунда бирерләр иде.

***Исламова Альбина, 11 класс***

Без татар балалары буларак, үзебезнең туган телебезне онытмаска, сакларга тиеш. Ләкин бөтен фәнне татарча уку бик дөрес түгел.Чөнки балалар уку йортына кергәч, төрле кыенлыклар белән очрашырга мөмкиннәр. Шуңа күрә русча уку яхшырак дип уйлыйм.

***Җиһангирова Талия, 11 класс***

Минемчә, татар телендә белем бирүнең ике ягы бар. Бер яктан,татар телендә укыту укучыларда туган телләренә карата мәхәббәт уятуга һәм дөрес сөйләшергә этәргеч була. Бу татар милләтенең үсеше өчен бик әһәмиятле. Ләкин, икенче яктан, югары уку йортында укырга теләгән балада фәнни терминнарны куллануда проблемалар туарга мөмкин. Чөнки уку йортында укыту рус телендә тормышка ашырыла. Урта мәктәптә саф татарча укыган бала мондый мохиткә эләккәч, югалып калырга мөмкин. Белүемчә, барлык фәннәрне татар телендә укытуны кертү, дәреслекләр белән тәэмин итү тулысынча уйланылып бетмәгән. Педагогик кадрларның да татарча укытуга махсус хәзерлекле булуы кирәк. Хәзергә татар теле дәресләре санын арттырырга һәм дәрестән тыш татарча түгәрәкләр һәм чаралар үткәрергә кирәк дип саныйм.

***Шәйгәрданова Регина, 11 класс***

Минемчә, рус телендә техник фәннәрне укырга җайлырак, чөнки уку йортларында лекцияләр рус телендә алып барылачак. Шуңа күрә бүгенге көндә мәктәпләрдә дәресләрне рус телендә алып бару әһәмиятле. Кайчандыр югары уку йортларында татар телендә белем бирүче төркемнәр булдырылган иде, белүемчә, алар исемдә генә калды. Авылда татарча белем алган укучыга шәһәрдә тел барьеры аркасында өстәмә авырлык тудыру кемгә кирәк?!

***Сәлимгәрәев Нурислам, 11 класс***

### Гимназия газетасын нинди форматта күрергә телисез?

***9а сыйныфы укучылары белән газетабыз турында сөйләштек.***

19 укучы кәгазь вариантны хуп күрә. Аны кулга тотарга, классташлар бергәләп карарга, фикерләшергә була.

Гайнетдинова Ильмира гәҗитне төсле рәсемле итеп күрергә теләвен әйтте.

Ибраһимова Алия гәҗит уку кешене компьютер һәм планшеттан аерып торачак, алар күзне боза, дигән фикер әйтте.

Газетаның электрон форматта булуын ике укучы хуп күрә.






### Гимназиянең 6б сыйныфы укучылары белән сер турында сөйләштек.

***Рената:*** *Сер – беркемгә дә белдерми торган фикер.*

***Руслан:*** *Серне саклый алмаган дус – дус түгел.*

***Лиана:*** *Сер бер кеше генә белгәндә сер була, ике кеше белсә, сер булудан туктый.*

***Айзат:*** *Серне саткан кеше сине дә сатачак.*

***Алина:*** *Серне бары тик әнигә генә сөйләргә кирәк. Кешеләргә киңәш бирергә ярый. Синең киңәшең башкаларга авыр хәлдән чыгарга ярдәм итәргә мөмкин. Ләкин теләсә кемгә сер сөйләргә ярамый.*

***Ислам:*** *Дуслык сер саклый белүдә сынала.*

***Диләрә:*** *Әнием – сер сандыгым. Мин барлык серләремне тик әниемә генә сөйлим. Серне әниләр генә саклый ала, башка кеше өчен синең серең кадерле түгел.*

**ТЫЛСЫМ+**

Октябрь-Ноябрь, 2016 нчы ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Шамукаева Эльвина, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Сәфәргалина Инзилә, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Шарифуллин Заһир
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym